| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|
| БОЛЬШЕКИБЯЧИНСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ КИБӘЧЕ АВЫЛ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| 422065, Республика Татарстан, Сабинский район, с. Большие Кибячи, ул.Ф.Энгельса, 21<br>тел. (84362) 42-6-24 | 422065, Татарстан Республикасы, Саба районы, Олы Кибәче авылы, Ф.Энгельс урамы, 21 йорт<br>тел. (84362) 42-6-24 |

e-mail: Bkib.sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

23.12.2025 №60

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Олы Кибәче авыл җирлеге территориясендә терекөмешле лампаларны туплау урыннарын булдыру турында

РФ Хөкүмәтенең “Яктырту җайланмаларын, электр лампаларын тиешенчә җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, урыннан-урынга күчерү һәм урнаштыру гражданнарның гомеренә һәм сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китереүе мөмкин булган өлешендә, җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләрен раслау турында” 28.12.2020 елгы №2314 карарының 5 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге территориясендә терекөмешле лампаларны туплау урыннары булдырырга, шул исәптән мондый туплау урыннарын оештыру күпфатирлы йортларда туплау урыннарын оештыру өчен урыннар булмау сәбәпле мөмкин булмаган очракларда, түбәндәге адрес буенча:

- Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, Олы Кибәче авылы, Ф.Энгельс ур., 21, Олы Кибәче авыл җирлегенең административ бинасы, 11 нче бүлмә.

2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге территориясендә терекөмешле лампалар туплану урыннарының урнашуы турында әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасында мондый урыннарның урнашуы турында мәгълүмат урнаштыру юлы белән, шулай ук мәгълүматны җирлекнең рәсми сайтында, җирлекнең түбәндәге адреслар буенча урнаштырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән

кулланучыларга хәбәр итәргә: ТР, Саба районы, Олы Кибәче авылы, Ф.Энгельс ур., 21; Төбәк авылы, Ленин ур., 28, Кече Кибәче авылы, К.Маркс ур., 50А.

3. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл башкарма комитетының «Терекөмешле лампаларны беренчел җыю һәм урнаштыру урыннарын раслау турында» 06.02.2014 елгы № 6 карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, җирлекнең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/kibiachi, шулай ук түбәндәге адреслар буенча урнаштырылган мәгълүмат стендларында: ТР, Саба районы, Олы Кибәче авылы, Ф. Энгельс ур., 21; Төбәк авылы, Ленин ур., 28, Кече Кибәче авылы, К. Маркс ур., 50А рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы А.К.Сафин